ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.04.2026 с.Старое Дрожжаное №120

Автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 21 февралендәге 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 12 декабрендәге 647 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәнең **5.2 пунктына** «даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «тиешле төрдәге маршрут реестрында язма» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче Р.И. Мөхәммәтҗанов